# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Ромодан авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 16 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ромодан авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Ромодан авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- тракторны карап тоту, асылмалы җиһазлар сатып алу(кар тәрткеч);
- үзйөрешле бензин кар җыю машинасын сатып алу;
- урамнарны яктыртуны карап тоту;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Ромодан авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән 10 көн эчендә Ромодан авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Ромодан авыл җирлеге башлыгы И.А.Чекалина